**МИНИСТЕРСТВО ПО ДЕЛАМ МОЛОДЕЖИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯШЬЛӘР ЭШЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**13.09.2018** **№24**

Казан шәһәре

Татарстан Республикасы Яшьләр
эшләре министры каршында
Иҗтимагый совет турында
Нигезләмәне раслау турында

2014 елның 21 июлендәге 212-ФЗ номерлы "Россия Федерациясендә җәмәгать контроле нигезләре турында" дип исемләнгән Федераль закон, 18.11.2010дагы 906 номерлы "Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы иҗтимагый совет турында" дип исемләнгән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә б о е р ы к бирәм:

1. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министры каршында Иҗтимагый совет турында Нигезләмәне расларга.
2. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча җаваплылыкны министрның беренче урынбасары Т.Ж.Сөйләймановка йөкләргә.

**Министр** **Д.И.Фәттахов**

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының
2018 елның 13 сентябрендәге
24 номерлы боерыгы белән
Расланган.

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯШЬЛӘР ЭШЛӘРЕ МИНИСТРЫ КАРШЫНДА ИҖТИМАГЫЙ СОВЕТ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет (моннан соң – Иҗтимагый совет) Татарстан Республикасында гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен, җәмәгать оешмаларының һәм башка коммерцияле булмаган оешмаларның дәүләт яшьләр сәясәтен формалаштырганда һәм тормышка ашыргандагы хокукларын, гражданнарның сыйфатлы хезмәт күрсәтүгә хокукларын, халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсен контрольдә тоту һәм тикшерү дәүләт системасын камилләштерү, шулай ук әлеге Нигезләмәдә күрсәтелгән башка бурычларны үтәү белән бәйле булган мәсьәләләрне карый торган Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы (моннан соң – министрлык) каршындагы киңәшләшү органы булып тора.

1.2. Иҗтимагый советның составы һәм катнашучылар саны, Татарстан Республикасы инистрлар Кабинеты тарафыннан расланган Министрлыклар каршында Җәмәгать советларын булдыру Тәртибе буенча Министрлык боерыгы нигезендә билгеләнә.

1.3. Үзенең эшчәнлегендә Иҗтимагый совет Россия Федерациясе Конституциясе, федераль конституцион законнар, федераль законнар, Россия Федерациясе президенты указлары һәм әмерләре, Россия Федерациясе Хакимияте

әмерләре һәм карарлары, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Президенты указлары һәм боерыклары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары, шулай ук әлеге Нигезләмә белән эш итә.

1.4. Иҗтимагый советның киңәшләре тәкъдим итү характерына ия.

1.5. Иҗтимагый совет үзенең эшчәнлеген иҗтимагый башлангычка нигезләнеп башкара.

1.6. Иҗтимагый совет эшчәнлеге ихтиярый характерга ия, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары кысаларында ихтиярыйлык, партнерлыкка ачык булу нигезендә эшли.

1.7. Иҗтимагый совет гражданлык җәмгыяте институтлары, дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре арасындагы уртак кызыксынулары нигезендә үзенең эшчәнлеген алып бара.

## 2. Иҗтимагый советның максатлары, бурычлары һәм вәкаләтләре

2.1. Иҗтимагый советның төп максатлары түбәндәгеләр:

гражданнар ихтыяҗларын һәм мәнфәгатьләрен исәпкә алу, гражданнар хокукларын һәм ирекләрен, иҗтимагый берләшмәләр һәм коммерцияле булмаган оешмаларның яшьләр сәясәте өлкәсендә дәүләт сәясәтен формалаштырганда һәм гамәлгә ашырганда дәүләтнеке булмаган коммерциячел булмаган бүтән оешмалар хокукларын яклау;

яшьләр сәясәте өлкәсенең төп юнәлешләрен булдыру, Министрлык эшчәнлегенең ачык булу принөибын тормышка ашыруга җәмәгать оешмалары, һөнәри һәм иҗатди берләшмә вәкилләрен чакыру;

Татарстан Республикасының дәүләт (муниципаль) оешмаларында тәкъдим ителә торган дәүләт (муниципаль) хезмәт сыйфатын җәмәгатьчелек тарафыннан контрольдә тотуны көчәйтү, Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәтен

тормышка ашыруда ачыклык, законлылык һәм профессиональлек принципларын үстерү.

2.2. Иҗтимагый совет бурычлары түбәндәгеләр була:

дәүләт яшьләр сәясәтен камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү;

дәүләт яшьләр сәясәте мәсьәләләренә кагылышлы норматив хокукый актлар проектларына иҗтимагый экспертиза уздыру, шул исәптән Министрлык тарафыннан әзерләнүче дәүләт программалары проектлары буенча фикер алышулар уздыру;

Министрлык тарафыннан карарлар кабул иткәндә иҗтимагый фикерне исәпкә алу механизмын камилләштерү;;

Министрлык эшчәнлегенең төп юнәлешләре буенча җәмәгатьчелекне мәгълүмат белән тәэмин итүне арттыру.

2.3. Иҗтимагый совет максатлары һәм бурычлары аның эш нәтиҗәләренә бәйле рәвештә, шулай ук Россия Федерациясендә икътисадый, социаль һәм сәяси вәзгыятьне исәпкә алып үзгәртелергә һәм аларга өстәмәләр кертелергә мөмкин.

## 3. Иҗтимагый совет составы

3.1. Иҗтимагый советның составы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган Министрлык, дәүләт комитеты, Татарстан Республикасы ведомствосы каршында Иҗтимагый совет формалашу турындагы Тәртип нигезендә формлаша.

3.2. Иҗтимагый совет Министрлык һәм Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы белән берлектә ихтиярый нигезлш формалаша, аның эшчәнлегендә 22 кеше катнаша.

3.3. Иҗтимагый совет составына гражданнар, шул исәптән иҗтимагый берләшмәләр һәм бүтән социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар вәкилләре булган гражданнар керергә мөмкин. Бу чакта аларның һөнәри сыйфатлары, шул исәптән белемнәре, Иҗтимагый совет алдына куела торган

мәсьәләләр буенча фикер алышу өчен кирәкле шушы өлкәдә эш тәҗрибәсе исәпкә алына.

Иҗтимагый совет составына, әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән затлар белән беррәттән, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы тәкъдим иткән затлар Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми санынының яртысын тәшкил итүче санда кертелә.

Иҗтимагый совет составына элегрәк Россия Федерациясе дәүләт вазыйфаларын, Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын, Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең бүтән субъектларының дәүләт вазыйфаларын, Татарстан Республикасы дәүләт граждан вазыйфаларын, муниципаль вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затлар Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми санының биштән береннән артмаган санда кертелергә мөмкин.

3.4. Россия Федерациясе дәүләт вазыйфаларын билүче затлар, Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче затлар, Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең бүтән субъектларының дәүләт вазыйфаларын билүче затлар, Татарстан Республикасы дәүләт граждан вазыйфаларын билүче затлар, муниципаль вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затлар, суд карары нигезендә хокукка сәләтсез дип танылган, бетерелмәгән яисә алынмаган хөкем ителеше булган затлар, шулай ук «Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы турында» 2005 елның 4 апрелендәге № 32-ФЗ Федераль закон нигезендәге башка затлар Иҗтимагый совет әгъзалары була алмый.

3.5. Министрлык Иҗтимагый совет составы билгеле булганнан соң, 30 көннән дә соңармыйча Иҗтимагый советның беренче утырышын оештыра. Беренче утырышта Иҗтимагый совет составыннан совет рәисе һәм урынбасары сайлана. Рәис һәм рәис урынбасары Иҗтимагый совет составындагы әгъзаларның гомуми санының күпчелеген исәпкә алу юлы белән ачык тавыш бирү аркылы сайлана.

3.6. Иҗтимагый совет рәисен һәм рәисе урынбасарын вазыйфасыннан азат итү турындагы мәсьәлә Татбашархив җитәкчесе мөрәҗәгате буенча карала, шулай

ук Иҗтимагый совет тарафыннан аларның шәхси гаризасы яисә Иҗтимагый советның барлык әгъзалары санының биштән бере тәкъдиме буенча карала.

3.7. Иҗтимагый совет рәисе Иҗтимагый совет әгъзалары арасыннан ачык тавыш бирү юлы белән сайлана.

3.8. Иҗтимагый совет әгъзаларының вәкаләтләре срогы Иҗтимагый советның формалашкан составы белән беренче утырыш булган көннән башлап 3 ел тәшкил итә.

3.9. Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләре Иҗтимагый совет рәисе тәкъдиме белән Министрлык тарафыннан түбәндәге очракларда туктатыла:

Россия Федерациясенең законнары нигезендә ул җинаять кылуда гаепләнә;

аңа административ арест рәвешендә административ җәза бирелә;

аны дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органына депутатлыкка кандидат итеп, җирле үзидарә органында сайланулы вазыйфага кандидат итеп, сәяси партиянең кандидатының ышанычлы заты яисә вәкаләтле вәкиле итеп теркәгән, шулай ук Россия Федерациясе референдумын уздыру буенча инициатив төркем составына керткән очракта.

3.10. Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләре түбәндәге очракларда туктатыла:

вәкаләтләренең срогы чыгу;

Иҗтимагый палата составыннан чыгу турында гариза тапшыру;

сәламәтлек күрсәткечләренә бәйле рәвештә аның Иҗтиманый совет эчшәнлегендә катнаша алмавы;

аңа карата судның гаепләү карары закон көченә кергән;

закон көченә кергән суд карары нигезендә аны хокукка сәләтсез яки хәбәрсез югалган дип тану;

аның тарафыннан әхлак нормалары дорфа рәвештә бозылган – Иҗтимагый советның Иҗтимагый совет утырышында катнашучы әгъзаларының гомуми санының күпчелек тавышы белән кабул ителгән карары буенча;

мәгълүм сәбәпләрсез Иҗтимагый совет утырышлары эшендә даими рәвештә (өч мәртәбәдән артык) катнашмау;

мәгълүм сәбәпләрсез Иҗтимагый совет рәисенең яисә рәисе урынбасарының йөкләмәләрен даими рәвештә (ике мәртәбәдән артык) үтәмәгү;

Россия Федерациясе дәүләт вазыйфасына, Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең бүтән субъектлары дәүләт вазыйфасына, Татарстан Республикасы дәүләт граждан вазыйфасына, муниципаль вазыйфага яисә муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләп куелуы;

башка дәүләт гражданлыгын алу;

Россия Федерациясе гражданлыгың туктатылуы.

3.11. Иҗтимагый советт әгъзаларының вазыйфаларын туктату Иҗтимагый совет әгъзасының язма гаризасы йә Иҗтимагый совет рәисенең яисә рәисе урынбасарының күрсәтүе нигезендә әзерләнгән Министрлык боерыгы, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 3.10 пунктында күрсәтелгән хәлләр ачыкланган очракта кабул ителгән карары нигезендә гамәлгә ашырыла..

Иҗтимагый совет әгъзасы Иҗтимагый совет рәисенә яки рәис урынбасарына әлеге Нигезләмәнең 3.10 пунктының дүрт, биш, ун-уникенче өлешләре турында хәбәр итәргә тиеш.

## 4. Иҗтимагый совет әгъзалары хокуклары һәм бурычлары

4.1 Иҗтимагый совет әгъзасы түбәндәге хокукларга ия:

Министрлык инициативасы буенча уздырыла торган барлык чараларда (утырышларда, киңәшмәләрдә, «түгәрәк өстәлләрдә» һәм башкаларда катнашырга), дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләре, шәхси күрсәткечләр турындагы белешмәләре булган мәгълүмат һәм куллану мөмкинлеге чикләнгән мәгълүмат куллануга бәйле рәвештә федераль законнар нигезендә керү чикләнгән чаралардан гайре;

инициатив тәртиптә аналитик язмалар, докладлар һәм башка мәгълүматаналитик материаллар әзерләргә һәм Иҗтимагый советка җибәрергә;;

Иҗтимагый совет рәисе аша Иҗтимагый советның эш планына һәм аның утырышлары көн тәртибенә тәкъдимнәр кертергә;

көн тәртибендәге мәсьәләләрне карауда катнашу өчен Иҗтимагый совет утырышына чакырылучы затларның кандидатуралары буенча тәкъдимнәр бирергә;

Иҗтимагый совет әгъзалыгыннан чыгарга..

4.2 Иҗтимагый совет әгъзасының бурычлары түбәндәгеләр:

Иҗтимагый совет рәисе тарафыннан бирелгән йөкләмәләрне үтәргә;

Иҗтимагый совет эшенең әлеге Нигезләмә белән каралган тәртибен белергә һәм үтәргә;

Иҗтимагый совет утырышларында шәхсән катнашырга;

үзенә йөкләнгән бурычларны хәл итү өчен эксперт, эш төркемнәре, комиссияләр, Иҗтимагый совет тарафыннан төзелә торган бүтән эшче органнар эшендә катнашырга.

## 5. Иҗтимагый советның эш тәртибе

5.1. Иҗтимагый совет үз эшен Иҗтимагый совет рәисе күрсәтмәсе буенча Иҗтимагый совет утырышында раслана торган планнар һәм программалар нигезендә оештыра..

5.2. Иҗтимагый совет эшен планлаштыру Иҗтимагый совет әгъзалары, Иҗтимагый совет рәисе һәм Татбашархив тәкъдимнәре нигезендә гамәлгә ашырыла.

5.3. Иҗтимагый совет утырышлары кварталга кимендә бер мәртәбә уздырыла. Иҗтимагый совет утырышларында кабул ителгән карарлар беркетмә белән рәсмиләштерелә.

Иҗтимагый совет утырышлары шулай Министрлык тарафыннан әзерләнә торган, 29.03.2013тәге 214 номерлы «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан әзерләнә торган, башкарма хакимияте органнар каршындагы иҗтимагый советлар утырышларында фикер алышудан башка кабул ителә алмый торган норматив хокукый актлар һәм бүтән документлар составын раслау турында» дип исемләнгән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карары белән

расланган Министрлык тарафыннан әзерләнә торган норматив хокукый актлар һәм бүтән документлар исемлегендә каралган, Министрлык тарафыннан әзерләнгән, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына теркәү өчен билгеләнгән тәртиптә җибәрелә торган норматив хокукый актлар проектларына бәяләмә бирү максатларында Министрлык инициативасы буенча уздырыла.

5.4. Иҗтимагый совет утырышлары, әгәр аларда Иҗтимагый совет әгъзаларының өчтән икесе катнашса, тулы хокуклы дип санала. Иҗтимагый совет әгъзасы шәхсән катнаша алмаган очракта, көн тәртибенә кертелгән мәсьәлә буенча үз тавышын һәм үз фикерен язма рәвештә, факсимиль яисә электрон почта аша Иҗтимагый советның бүтән әгъзасына тапшырырга мөмкин, ул бу хакта Иҗтимагый совет рәисенә яисә рәисе урынбасарына, яисә Иҗтимагый совет секретарена алдан хәбәр итәргә тиеш. Иҗтимагый совет утырышында катнашучы әгъзалар санына үз тавышларын Иҗтимагый советның бүтән әгъзаларына ышанып тапшырган Иҗтимагый совет әгъзалары да өстәлә.

Иҗтимагый совет тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 5.3 пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән норматив хокукый актлар проектларын (норматив хокукый актларны) карау Министрлык тарафыннан аларны Иҗтимагый советка җибәргән көннән ун календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла. Бу чакта Иҗтимагый совет бәяләмәләрен бирү максатларында тавыш бирүне уздыру алар буенча читтән торып, Иҗтимагый советның барлык әгъзаларын сораштыру рәвешендә гамәлгә ашырылырга мөмкин, сораштыру нәтиҗәләре Иҗтимагый совет рәисе тарафыннан имзалана торган, ә ул булмаганда – Иҗтимагый совет рәисе урынбасары тарафыннан имзалана торган беркетмәгә кертелә. Мондый тавыш бирү почта, телеграф, телетайп аша, телефон, электрон яисә тапшырыла торган һәм кабул ителә торган хәбәрләрнең хакыйкый булуын һәм аларның документаль расланышын тәэмин итәрлек бүтән төр элемтә чарлары аша документлар алмашу юлы белән уздырылырга мөмкин. Читтән торып тавыш бирү уздырган очракта, Иҗтимагый совет рәисенең урынбасарына, барлык әгъзаларына тәкъдим ителүче көн тәртибе, Иҗтимагый совет тарафыннан бәяләмә бирелергә тиешле норматив хокукый акт

проекты (норматив хокукый акт) җибәрелә. Иҗтимагый совет әгъзалары кирәк чакта карала торган норматив хокукый акт проекты (норматив хокукый акт) буенча Министрлык өстәмә материаллар һәм мәгълүмат соратып ала алалар.

Иҗтимагый совет карарлары гади күпчелек тавыш белән кабул ителә.

5.5. Иҗтимагый совет утырышларын Иҗтимагый совет рәисе уздыра, ә ул булмаган очракта – Иҗтимагый совет рәисе урынбасары.

5.6. Иҗтимагый советның аңа йөкләнгән максатлар, бурычлар, вәкаләтләр нигезендә кабул ителә торган карарлары тәкъдим итү характерында була һәм кызыксынучы затларга Иҗтимагый совет утырышы беркетмәсеннән өземтә рәвешендә яисә Иҗтимагый совет карары буенча бүтән алым белән җиткерелә..

5.7. Иҗтимагый совет эшчәнлеге турындагы мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Министрлык сайтында «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет» бүлегендә урнаштырыла.

5.8. Иҗтимагый совет рәисе:

Иҗтимагый совет эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итә;

Иҗтимагый совет утырышын алып бара;

Иҗтимагый совет әгъзалары тәкъдимнәре нигезендә Иҗтимагый совет эше планын әзерли, шулай ук аларга үзгәрешләр кертә һәм Иҗтимагый совет раславына тәкъдим итә;

Иҗтимагый совет утырышын оештыра;

Иҗтимагый совет утырышының көн тәртибен раслый;

Иҗтимагый совет рекомендацияләренә, беркетмәләренә һәм Иҗтимагый советның бүтән документларына имза сала;

Иҗтимагый совет утырышларын уздыру вакытын һәм урынын билгели;

Иҗтимагый совет эшчәнлеге, аңа йөкләнгән максатлар һәм бурычлар кысаларында Иҗтимагый совет әгъзаларына йөкләмәләр бирә;

запросларны, рекомендацияләрне, тәкъдимнәрне, җавапларны, аңлатуларны һәм мөрәҗәгатьләрне Иҗтимагый совет исеменнән имзалый.

5.9. Иҗтимагый совет рәисе урынбасары:

Иҗтимагый совет рәисе булмаган вакытта аның функцияләрен үти;

Иҗтимагый совет утырышларын әзерләүне оештыра;

Иҗтимагый совет утырышлары көн тәртибен төзи һәм аны Иҗтимагый совет рәисе раславына тәкъдим итә;

Иҗтимагый совет рәисе кушуы буенча Иҗтимагый совет эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле бүтән функцияләрне гамәлгә ашыра.

5.10. Иҗтимагый советның җаваплы сәркатибе:

утырышларга материаллар һәм карарлар проектын әзерләүне оештыра;

Иҗтимагый совет әгъзаларына Иҗтимагый совет утырышын уздыру вакыты һәм урыны, көн тәртибе турында хәбәр итә, аларны кирәкле мәгълүмат-белешмә материаллары белән тәэмин итә;

Иҗтимагый советның һәм башкарма органның оештыру хезмәттәшлеген тәэмин итә;

Иҗтимагый совет эшчәнлеген документаль-техник тәэмин итүне гамәлгә ашыра;

Иҗтимагый совет утырышлары беркетмәләрен рәсмиләштерә һәм кабул ителгән карарларны тикшереп торуны гамәлгә ашыра;

Иҗтимагый совет утырышлары көн тәртибен төзүдә катнаша.

5.11. Иҗтимагый совет әгъзалары Иҗтимагый совет утырышларында тыңлауга һәм фикер алышуга чыгарыла торган мәсьәләләрне әзерләү өчен эш, эксперт төркемнәренә һәм бүтән эшче төркемнәргә берләшергә, Иҗтимагый совет составына кермәүче белгечләрне Иҗтимагый совет рәисе урынбасары белән килештерү буенча материаллар әзерләүгә җәлеп итәргә мөмкин.

5.12. Иҗтимагый совет карары буенча Иҗтимагый совет утырышына башкарма хакимияте органнары, коммерциячел булмаган оешмалар, фәнни учреждениеләр вәкилләре, экспертлар һәм кирәкле белешмәләр һәм Иҗтимагый  совет тарафыннан карала торган мәсьәләләр буенча бәяләмәләр бирү өчен башка белгечләр дә чакырылырга мөмкин. Иҗтимагый совет әгъзалары булмаган массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре Иҗтимагый совет утырышларында Иҗтимагый совет чакыруы буенча катнашырга мөмкин.

5.13. Иҗтимагый совет үзенең эшчәнлегендә Татарстан Республикасы Иҗтимагый советы әгъзаларының катнашуын тәэми итә.

5.14. Иҗтимагый совет каравына кертелә торган материаллар, Иҗтимагый советның әлеге мәсьәләләр каралырга тиешле утырышын уздыру көне билгеләнгәннән соң ун календарь көннән дә соңга калмыйча, Иҗтимагый совет рәисе урынбасарына тапшырылырга тиеш. Материалларны соңрак срокларда тапшыру Иҗтимагый совет рәисе яисә рәисе урынбасары белән килештерелә.

5.15. Иҗтимагый совет эшчәнлеген техник һәм оештыру ягыннан тәэмин итү Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.